Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Кырынды авыл җирлегенең Еленовский торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 19 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең Еленовский авылында гражданнар җыены **карар бирде**:

1. Кырынды авыл җирлеге Еленовский авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белеем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзарасалым акчасын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле һәм ияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Еленовский авылындагы Кызыл урамы буенча юлны ремонтлау һәм вак таш җәю.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукыйактларырегистрынакертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәисле китүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе И. И. ЗАКИРОВ